# ХОДАЙ ИМАНЫ

Аллага жараулы булыйым дигян кешегя Алла кыуаты киряк. Ул кыуатны Алла Ӱзеня ышанганга, бойорокларын тотканга, теляк итеб торганга гына биря. Теляк итеӯ кюҥелне Аллага кютяреб, Аннан киряклене сорау. Ничек теляргя Ходай Ӱзе иман ӧйряткян. Христоснын апостолларга ӧйряткян иманы:

ЭЙ КЮКТЯГЕ АТАБЫЗ! ДАННЫ БУЛЫБ ТОРСОН ИСЕМЕҤ СИНЕҤ, КИЛСЕН ПАДШАЛЫГЫҤ СИНЕҤ, ЖИРДЯ ДЯ КЮКТЯГЕЧЯ БУЛСЫН ИРКЕҤ СИНЕҤ, БӦГӦН КӦННӦК ИКМЯГЕБЕЗНЕ БИР БЕЗГЯ, БУРЫЧЛАРЫБЫЗНЫ КИЧЕР, БЕЗ ДЯ БЕЗГЯ БУРЫЧЛЫ БУЛГАННАРГА КИЧЕРГЯН КЮК, БЕЗНЕ АЛДАНЫРГА ИРЕК ЖИБЯРМЯ, ЖАМАННАН КОТКАР БЕЗНЕ.

Алланы Кюктяге Атабыз диб айтергя Христос Ӱзе ӧйряткян. Ул кешелекне арыуландырыу белян, кешелярне Алла Атасы белян татыуландырган.

**Данны булыб торсон исемеҥ Синеҥ**

Бу беренче сораудa без соройбыз: арыу исемеҥне чын кюҥелдян кадерляб торсак ыйы диб, гадел тороб, кешеляр арасында данналдырсак ыйы диб соройбыз.

**Килсен Падшалыгыҥ Синеҥ**

Бу сораудa Алладан: безгя Син падшалык итсяҥ эйе, безне жазык алыб узмасын ыйы, ӓммя безне Синеҥ Тыныҥ арыуга ӧйрятеб, саклаб жӧртсӧн эйе диб соройбыз.

**Жирдя дя Кюктягечя булсын иркеҥ Синеҥ**

Бу сораудa Алладан: безгя Ӱз иркенчя кылсаҥ эйе, Кюктяге пяриштяляр, изгеляр Синеҥ иркеҥне кылыб торган кюк, без жирдягеляр дя Сиҥа баш салыб, Син кушканны кылыб торсак ыйы диб соройбыз.

**Бӧгӧн кӧннӧк икмягебезне бир безгя**

Бу сораудa Алладан: безгя кӧнгя житярлек ашамнык, эчемнек, тормошка киряклене бир диб соройбыз. Кешенен тяне, жаны бар. Тяне икмяк ашаб, жаны Алла кыуаты, дяӯляте белян ныгая, шуҥар кюря Алладан безгя сюзеҥне эшеттерсяҥ эйе, Ӧлӧш алдырсаҥ ыйы диб телейбез.

**Бурычларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк**

Бу сораудa Алладан: безгя жазыклы, гайебле булганнарга, безне рянжеткянняргя без кичерябез; без аларга кичергян кюк, Син дя безгя гайеблyребезне, жазыкларыбызны кичер диб соройбыз. Ходайга да, кешегя дя кыласы арыулыкны кылмый калгач, бурычлы булыб торабыз. Бурычлар диб жазыклар айтеля.

**Безне алданырга ирек жибярмя**

Бу сораудa Алладан: безне алданырга ирек жибярмя, сыналырга туры китермя диб соройбыз. Безне алдарга, аздырырга шайтанны да, усал кешене дя ирек жибярмя диб соройбыз. Ӓгяр кызыгырдый эшкя, жя кешегя, жя нястягя туры килсяк, алданмый калырга, жазыкка батмаска безгя Ӱзеҥ булыш диб соройбыз.

**Жаманнан коткар безне**

Бу сораудa Кюктяге Атабыздан: безне Алладан, деннян бизяргя, ӓр-тӧрлӧ усаллыкка котортоучы шайтаннан, дошманнан коткар, бялядян, чирдян сакла диб соройбыз.

***Ӧй-хужалыгында кулланмаска***
***В хозяйственных целях не использовать!***